ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕМЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Г.Тукая, д.63а, д. Шемяк,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422140

Г.Тукай ур., 63а нче а йорт, Шәмәк авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-68-37; e-mail: Shmk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
№ 1

Карар
29.01.2026 ел.

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), «Татарстан Республикасында «җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә Шәмәк авыл башкарма комитеты Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирлекләре КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарга 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 9678 сум 63 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.01.2025 ел № 1 карарын гамәлдән чыгарырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче: /И.Н.Зыятдинов/

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.01.2026 ел № 1 карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлегендә вафат булганнарның (һәлак булганнарның) ире, якын туганнары, башка туганнары, йә вафат булган кешенең законлы вәкиле булганнарны җирләүгә гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә 01.02.2026 елдан Бәяләр

| Хезмәтләратамасы | Хезмәтләрбәясе, сумнарда |
|---|---|
| 1. Җирләүөченкирәкледокументларнырәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Каберне һәмкүмүөченкирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4452,21 |
| 3.Үлгән кешенеңгәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1160,20 |
| 4. Күмү (кабер казу һәмкүмү) | 4066,33 |
| **БАРЛЫГЫ** | 9678,63 |

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.01.2026 ел № 1 карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәмәк авыл җирлегендә вафат булганнарның (һәлак булганнарның) ире, якын туганнары, башка туганнары, йә вафат булган кешенең законлы вәкиле булмаганнарны җирләүгә гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә 01.02.2026 елдан Бәяләр

| Хезмәтләратамасы | Хезмәтләрбәясе, сумнарда |
|---|---|
| 1. Җирләүөченкирәкледокументларнырәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Тәннеңкиеме | 1381,27 |
| 3Каберне һәмкүмүөченкирәкле башка әйберләрнебирүһәмкитерү | 3197,37 |
| 4Үлгән кешенеңгәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1183,58 |
| 5. Күмү (кабер казу һәмкүмү) | 3916,42 |
| **БАРЛЫГЫ** | 9678,63 |